СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.08.2021 г. Заинск № 66

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 29 октябрендәге 129 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 декабрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты турында фикер алышу» гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм «Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында» бәяләмә нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 29 октябрендәге 129 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- линияле объектны - 16:48:090102:165, 16:48090102:166, 16:48:090102:167, 16:48:090101:3252 кадастр номерлы җир кишәрлекләре чикләрендәге резерв газүткәргечне урнаштыру максатыннан, СХ-4 зонасы территориясен (бакчачылык һәм дача хуҗалыгы зонасы) И2 инженерлык инфраструктурасы зонасына күчерү өлешендә;

- ТР, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, Җиңү проспекты, 34В позициясе адресы буенча урнашкан, гомуми мәйданы 900 кв.м булган 16:48:060102:2252 кадастр номерлы җир кишәрлеген С1 зонасыннан (склад

объектлары зонасы) ОД-1 зонасына (күп функцияле иҗтимагый-эшлекле төзелеш зонасы) (3.8 - иҗтимагый идарә) үзгәртү өлешендә;

- VI бүлекнең 20 статьясы 3 пунктына ике пункча өстәргә: Комиссиягә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр җибәрелә:

- Россия Федерациясе тарафыннан төзелгән һәм территорияне комплекслы үстерү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән карарның гамәлгә ашырылуын тәэмин итүче вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы яисә юридик зат тарафыннан;

- территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул иткән Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы, җирле үзидарә органы, Россия Федерациясе субъекты тарафыннан төзелгән һәм территорияләрне комплекслы үстерү турында Россия Федерациясе субъекты тарафыннан кабул ителгән карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат яисә территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыру максатларында территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат тарафыннан.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының җир мәсьәләләре, экология һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Әгъләмов Р.В.).

**Совет Рәисе** **Р. Г. Кәримов**